РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы, Азнакай
районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» октябрь 2022 ел № 38

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда каралган бурычларны үтәүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 24 октябрендәге 38нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2022 елның 14 июлендәге 266-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 30 статьясындагы ундүртенче өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда каралган бурычларны үтәүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 24 октябрендәге 38нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге башкарма комитетында шәхси мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре» 1 нче кушымтаның 2 бүлегенең 1.3 пунктында «зыянны бәяләү» сүзләреннән соң «субъектларның шәхси белешмәләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле орган билгеләгән таләпләр нигезендә» сүзләрен өстәргә.

1.2. «Шәхси мәгълүматлар субъектларының яисә аларның вәкилләренең Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге башкарма комитетында персональ белешмәләргә керү мөмкинлеген карау кагыйдәләре» 2 нче кушымтада:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әгәр федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны бирү һәм (яисә) оператор тарафыннан шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык алу мәҗбүри булса, оператор шәхси белешмәләр субъектына аның шәхси мәгълүматларын бирүдән баш тартуның юридик нәтиҗәләрен аңлатырга һәм (яисә) аларны эшкәртүгә ризалык бирергә тиеш.»;

б) 11 пунктта «30 (утыз) көн» сүзләрен «ун эш көне» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма оператор тарафыннан соратылган мәгълүматны бирү вакытын озайту сәбәпләрен күрсәтеп, мотивлаштырылган хәбәрнамәнең субъектлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле орган адресына җибәрелгәндә биш эш көненә артыграк булмаска тиеш.».

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Азнакай муниципаль районы сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: З.Ә. Идрисов.